РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ГЛАВА ТЮРНЯСЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТӨРНӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | Төрнәс ав. | КАРАР

« 2» ноябрь 2020 ел | № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 15 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Кызыл Армия урамы 25нче йорт адресы буенча урнашкан ФАП янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Көнчыгыш, Юл буе, Кызыл Армия, Кутузов, Суворов, Ворошилов, Көнбатыш, Совет, Көнбатыш тыкрыгы, Совет тыкрыгындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 15 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Мәктәп урамы 54нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Мәктәп урамы, Завод урамы, Мәктәп тыкрыгы урамнарындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 15 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Үзәк урам буенча 51нче йорт адресы буенча урнашкан авыл җирлеге бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Үзәк урамы, Елга Арьягы урамы, Күл урамы, Бакча урамнарындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2020 елның 21 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Яшьләр урамы буенча 6нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Яшьләр, Кыр урамнарындагы йортлардан үзара

салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Төрнәс авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның  тол калган хатыннарыннан,  көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан  кала,  1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган  акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне  хәл итүгә җибәрергә ризамы:

- Төрнәс авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм күтәртеп, төзәтеп чыгу;
- Төрнәс авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтү, товарлар сатып алу;
- Төрнәс авылында ю Төрнәс авылында Җиңү паркын төзекләндерү лларны сезонлы карап тоту;
- Төрнәс авылында Җиңү паркын төзекләндерү;
- Төрнәс авылында су белән тәэмин итү чыганакларын (янгын гидрантлары өчен кое, скважиналарны лицензияләү) норматив хәлгә китерү;
- МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар сатып алу;
- Төрнәс авылында 3 данә күләмендә җәяүлеләр  күперчеген ремонтлау;
- Төрнәс авылында 3 данә кое бораулау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

9. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В. Белов